**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2024 елның 22 октябрендәге 4462 номерлы карары**

**Капиталь төзелеш объектының**
**архитектура-шәһәр төзелеше ягыннан тышкы күренешен**
**килештерү кагыйдәләрен һәм тәртибен үзгәртү турында**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 30 статьясындагы 5.3 өлеше, 6 өлешенең 2.1 пункты, 6.2 өлеше нигезендә, 2022 елның 29 декабрендәге 612-ФЗ номерлы «Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында һәм “Россия Федерациясендә тимер юл транспорты турында”гы федераль законның 16 статьясындагы 2 пунктының икенче абзацы гамәлдән чыгуын тану хакында»гы федераль законның 5 статьясындагы 4, 5 өлешләренә таянып, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2023 елның 29 маендагы 857 номерлы «Капиталь төзелеш объектының архитектура-шәһәр төзелеше ягыннан тышкы күренешенә таләпләрне һәм Капиталь төзелеш объектының архитектура-шәһәр төзелеше ягыннан тышкы күренешен килештерү кагыйдәләрен раслау турында»гы карары нигезендә **карар бирәм:**

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2016 елның 13 октябрендәге 4130 номерлы «Казан шәһәре Башкарма комитеты тарафыннан объектның (проектлана һәм реконструкцияләнә торган капиталь төзелеш объектларының, керү урыннарының һәм төзекләндерү объектларының) архитектура-шәһәр төзелеше ягыннан тышкы күренешен килештерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында»гы карарын, Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесенең 2008 елның 30 июлендәге 4157 номерлы «Җирдән файдалану һәм төзелеш мәсьәләләре турында»гы карарын гамәлдән чыккан дип танырга.

2. Капиталь төзелеш объектларының архитектура-шәһәр төзелеше ягыннан тышкы күренешен килештергәндә, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2023 елның 29 маендагы 857 номерлы «Капиталь төзелеш объектының архитектура-шәһәр төзелеше ягыннан тышкы күренешенә таләпләрне һәм Капиталь төзелеш объектының архитектура-шәһәр төзелеше ягыннан тышкы

күренешен килештерү кагыйдәләрен раслау турында»гы карары белән билгеләнгән килештерү тәртибе нигезендә эш итү зарур дип билгеләргә.

3. Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2023 елның 29 маендагы 857 номерлы «Капиталь төзелеш объектының архитектура-шәһәр төзелеше ягыннан тышкы күренешенә таләпләрне һәм Капиталь төзелеш объектының архитектура-шәһәр төзелеше ягыннан тышкы күренешен килештерү кагыйдәләрен раслау турында»гы карары белән расланган Капиталь төзелеш объектының архитектура-шәһәр төзелеше ягыннан тышкы күренешен килештерү кагыйдәләренең 3 пунктын үтәү йөзеннән, Казан шәһәре Башкарма комитеты Казан шәһәре Башкарма комитетының 2012 елның 13 ноябрендәге 8200 номерлы «Казан шәһәренең Шәһәр төзелеше советы турында»гы карары нигезендә Казан шәһәренең Шәһәр төзелеше советы әгъзаларын капиталь төзелеш объектларының архитектура-шәһәр төзелеше ягыннан тышкы кыяфәтен килештерүдә катнашуга җәлеп итәргә хокуклы дип билгеләргә.

4. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырып чыгарырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

5. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән гамәлгә керә дип билгеләргә.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесенең беренче урынбасары А.Р.Нигъмәтҗановка йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**